**Республика Татарстан**
**Палата имущественных и земельных отношений Заинского муниципального района**

ул.Автозаводская, д.1 А,
г.Заинск, Республика Татарстан 423520
тел. 8(85558)2-80-31,
2-80-32,2-80-33, 2-80-34
E-mail: Pzio.Zainsk@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районының милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы**

Автозавод урамы, 1 а йорт,
Зәй шәһәре Татарстан Республикасы, 423520
тел. 8(85558)2-80-31,
2-80-32,2-80-33, 2-80-34
E-mail: Pzio.Zainsk@tatar.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

«26» 12 2024ел. №1040П

**«Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар уздырмыйча милеккә , арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» карарына таянып",Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы турында нигезләмә белән

**боерык бирә:**

1. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар уздырмыйча милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын кушымта нигезендә расларга.
2. Зәй муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасының 2021 елның 27 сентябрендәге 682П номерлы «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең

административ регламентын раслау турында» боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Зәй муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасының 2022 елның 27 маендагы 306П номерлы «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында" боерык үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының җир мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы Т.Н. Кузнецовага йөкләргә.

**Палата рәисе** **Р.Р. Шәйхиев**

Юрисконсульт